СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2020 Әгерҗе шәһәре № 48-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы прокуратурасының ««Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, (Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керү өлешендә) административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2013 елның 01 февралендәге 21-2 номерлы карарына 2020 елның 04 июнендәге 02-08-01/98 номерлы протестын үтәү максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 апрелендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 пунктының 5 пунктчасы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, (Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керү өлешендә) административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2013 елның 01 февралендәге 21-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.Т. НУРИСЛАМОВ

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының
«23» 06 2020 ел, № 48-3
карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен пеня, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафлар һәм аренда түләве буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) аларны түләтү икътисадый, социаль-юридик характердагы сәбәпләр аркасында мөмкин булмаган Әгерҗе муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен (алга таба - мөлкәт) файдаланган өчен арендаторлар бурычларын исәпкә алуда реаль чагылыш табу максатларында, гамәлдәге законнар нигезендә эшләнде.

Билгеләнгән вакытта түләнмәгән бюджетка түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түбәндәге очракта түләтүгә өметсез дип таныла:

1) физик зат - бюджетка түләүче үлсә яисә ул Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан ителсә;

2) шәхси эшмәкәр - бюджетка түләүче, «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, бурычлының мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә банкрот дип танылса;

2.1) шәхси эшмәкәр булмаган зат- бюджетка түләүче, «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә бонкрот дип танылса;

3) оешма - бюджетка түләүче оешманың мөлкәте җитмәгәнлектән һәм (яисә) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аны түли алмавы сәбәпле түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә бетерелгән (ликвидацияләнгән) дип танылса;

4) аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта торган штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яки кичерү турында актлар кулланылса;

5) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма производствоны тәмамлау һәм башкарма документны түләтүчегә кайтару турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарылса, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык узган булса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмаса;

суд тарафыннан бюджетка түләүләрне түләүчене банкрот дип тану турында гариза кире кайтарылса яки банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш буенча эш туктатылса;

6) юридик зат юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан теркәү органы карары буенча төшереп калдырылуы һәм «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документ алучысына әйләнеп кайту сәбәпле башкарма производствоны тәмамлау турында элек чыгарылган суд приставы-башкарма карар булу-булмавы - оешмалар мөлкәтенең җитмәве һәм әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны юкка чыгару мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә. «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында терки торган орган карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә ышанычсыз дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылырга тиеш.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясының 1 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар түләтүгә өметсез дип таныла, әгәр, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турындагы карарның үтәлешен туктату турында карар чыгарылса.

Муниципаль җир контроле нәтиҗәсендә билгеләнгән срокта түләнмәгән Әгерҗе муниципаль районы бюджетына күчерелә торган административ штрафлар, амнистия турында актлар кулланылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән очракта, түләтүгә ышанычсыз дип таныла, аның нигезендә Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы бюджет керемнәре администраторы буларак штрафлар буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалтса.

## II. Бурычларны түләтүгә өметсез булганнарны исәптән чыгару тәртибе

Аренда түләве буенча бурычларны, Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен пеня, шулай ук муниципаль җир контроле нәтиҗәсендә салынган Әгерҗе муниципаль районы бюджетына күчерелә торган административ штрафларны түләттерүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары

белән расланган комиссия тарафыннан кабул ителә.

Бурычларны түләтүгә өметсез булганнарны исәптән алу комиссиясе кергән документларны әлеге Нигезләмә нигезендә алар тапшырылган вакыттан алып 30 көннән дә соңга калмыйча карый.

Комиссия карары документларны карауда катнашкан комиссия рәисе һәм барлык әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## III. Аренда түләве, мөлкәтне һәм административ штрафларны файдаланган өчен пенялар түләтүгә өметсез бурычларны исәптән чыгару өчен кирәкле документлар исемлеге

Бурычны түләтүгә һәм исәптән алуга өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге төп документлар булганда кабул ителә:

1. Гамәлдәге законнар нигезендә оешма бетерелгән (ликвидацияләнгән) очракта:

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

- Юридик затны - бурычлы-арендаторны бетерү (ликвидацияләү) турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр.

2. Бурычлыны "Бөлгенлек (банкротлык) турында" Федераль закон нигезендә бөлген (банкрот) дип таныган очракта - бурычлының мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән бурыч өлешендә:

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

- Арбитраж судның арбитраж суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган бурычлыга карата конкурс производствосын тәмамлау турында билгеләү күчермәләре.

3. Бурычлы үлгән яки суд тарафыннан үлгән дип игълан ителгән очракта (варислар булмаса; әхлаксыз дип табылса яисә килешүдә бурычлы үлгән очракта йөкләмәләрне туктату каралган очракта):

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

- арендатор-физик затның үлеме турында таныклык күчермәләре яки физик зат-арендаторны вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәләре;

-варистан бурычны түләтү мөмкинлеген раслый торган яки вафат булган яисә суд тарафыннан вафат булган дип игълан ителгән физик затның-арендаторның мирас мөлкәтенең дәүләткә күчешен раслый торган документ (варисларның закон буенча да, васыять буенча да булмавын раслаучы, варисларның берсе дә варислардан мирас итеп алырга хокуклы түгел яки барлык варисларның берсе дә варислыкны кабул итмәгән, яки барлык варислар да мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын белдермәгән тиешле нотариус белешмәсе).

4. Суд приставының башкарма производствоны тәмамлау турында һәм түләттерү мөмкин булмауга бәйле рәвештә башкарма документны кире кайтару турында карары булган очракта:

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

- башкарма производствоны тәмамлау һәм башкарма документны кире кайтару турында суд приставы карары.

5. Бурыч түләттерү турында таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тартучы законлы көченә кергән суд актлары булган очракта:

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

- законлы көченә кергән бурычны түләтү турындагы таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында суд акты.

6. Бурычлыны булмаган дип таныган очракта:

- исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;
- бурычлы оешманы теркәү урыны һәм урнашкан урыны турында мәгълүмат булмау турында салым органы документы йә арендатор-физик затны хәбәрсез югалган дип игълан итү турында суд карары күчермәсе;
- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органнардан милек хокукында күчемсез мөлкәткә ия арендтор турында мәгълүмат булмау хакында белешмәләр;
- милек хокукында арендаторга караган күчемле мөлкәтнең булмавы турында белешмәләр.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

Комиссия тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерә һәм бурычларны исәптән чыгару турында яисә исәптән чыгарудан баш тарту турында карар кабул итә. Карарлар һәр арендатор буенча индивидуаль кабул ителә.

Бурычны түләтүгә һәм исәптән алуга өметсез дип тану турындагы карар комиссия тарафыннан өч нөсхәдә рәсмиләштерелә.

Бурычны исәптән чыгару белән бәйле үзгәрешләр, бурычны исәптән чыгару турында карар кабул ителгән айдан соң килүче айның беренче санына хисаплылыкка кертелә.

Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль җир контроле нәтиҗәсендә салынган Әгерҗе муниципаль районы бюджетына күчерелә торган административ штрафны, муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен, аренда түләве буенча бурычларны түләттерү һәм исәптән төшерү өчен өметсез дип тану турындагы документларны исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итә.